| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРЫНДЫК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елнның 20 марты Борындык ав. № 5

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Борындык авыл җирлеге Башкарма комитетына
гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтына урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты
Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Р.Гайнетдинов

Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020е. «20» мартының 5 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Борындык авыл җирлеге Башкарма комитетына
гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, җәмәгатьчелек фикерен һәм актуаль проблемаларны өйрәнү, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатыннан үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау барлык мөрәҗәгатьләр, шул исәптән язма рәвештә, Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ формасында, шулай ук вәкаләтле затларның гражданнарны кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча тормышка ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен башкарыла.

5.Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм күчмә кабул итү, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ тиешле чорда узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре аналитик белешмәне ел саен Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://burduk-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтындагы «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килә торган айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.